ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2021 ел Баулы шәһәре №57

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының халыкка
хәбәр итү системаларының әзерлеген
комплекслы тикшерү һәм хәбәр итү
системасының техник чаралары торышын
бәяләү буенча комиссия төзү турында

Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы һәм ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген комплекслы тикшерүне оештыру, шулай ук хәбәр итү системасының техник чараларының торышын бәяләү максатларында, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Россия Цифрлаштыру министрлыгы «Халыкка хәбәр итү системалары турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 578/365 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына хәбәр итүне эксплуатацияләү-техник хезмәт күрсәтүне оештыру нигезләмәсен раслау турында» 2020 елның 24 декабрендәге П/504/414 номерлы боерыгы таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районының халыкка хәбәр итү системасының һәм ашыгыч хәбәр итү комплекслы системасының әзерлеген комплекслы тикшерү, шулай ук хәбәр итү системасының техник чаралары торышын бәяләү буенча түбәндәге составта даими эшләүче комиссия төзергә:

Гозәеров И.И. - Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Гарифуллина Г.Л. - Баулы муниципаль районының “Гражданнарны яклау идарәсе” МКУ җитәкчесе;

Давыдов Н.Б. - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Баулы муниципаль районы буенча гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты (килешү буенча);

Фомин В.П. - «Таттелеком» ГАҖ Әлмәт ЗУЭС Баулы РУЭС начальнигы (килешү буенча).

2. Комиссия билгеләнгән вакытта халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы һәм ашыгыч хәбәр итүнең комплексы системасы әзерлегенә комплекслы тикшерүләр уздырырга тиеш. Тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документларны әзерләргә:

- муниципаль хәбәр итү системасы, шул исәптән халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплексы системасы әзерлеген комплексы тикшерү нәтиҗәләре буенча акт;

- муниципаль хәбәр итү системасының техник чараларының техник торышын бәяләү нәтиҗәләре буенча акт;

- муниципаль хәбәр итү системасының техник чараларына (ТО-2) техник хезмәт күрсәтү акты;

- КСЭОН халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы паспорты.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров